КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 октябрь г.Казань № 1075

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 485 нче; 2018 ел, 24 август, 697 нче; 2019 ел, 19 апрель, 309 нчы; 2019 ел, 15 май, 394 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1177 нче; 2020 ел, 6 март, 179 нчы; 2020 ел, 21 сентябрь, 849 нчы; 2021 ел, 13 апрель, 244 нче, 2021 ел, 6 октябрь, 956 нчы, 2022 ел, 25 март, 271 нче, 2022 ел, 29 июль, 731 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә инистрлыгы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, «Яңа Гасыр» теле-радиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе, Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе), Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы мәдәниятне үстерү фонды, «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль бюджет югары белем бирү учреждениесе, «Татарстан Республикасы

предприятиеләре һәм оешмалары яшьләре берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы, «Артиас» иҗат хезмәткәрләре берләшмәсе» Казан шәһәр иҗтимагый оешмасы, «Созвездие-Йолдызлык» Татарстан Республикасы төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы белән берлектә «Наше время - Безнең заман» эшләүче яшьләрнең ел саен ачык республика телевизион иҗат фестивален үткәрү турында тәкъдимен кабул итәргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин